ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.10.2022 г. Заинск № 512

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар аш белән тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар аш белән тукландыруның уртача бәясен раслау турында**

«Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар ризык белән тукландыруның уртача бәясен раслау турында» 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пункты нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Расларга:

муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар аш белән тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны бер укучыга көненә 2023 елга 66,76 сум, 2024 елга – 61,30 сум, 2025 елга 69,43 сум күләмендә;

башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар аш белән тукландыруның уртача бәясен көненә 2023 елга 64,19 сум, 2024 елга – 66,76 сум, 2025 елга – 69,43 сум күләмендә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42